# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Күгәй авыл җирлегенең Күгәй авылында халык җыены нәтиҗәләре турында**

**2025 елның 15 ноябре**

**№2**

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары белән, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә гражданнар җыены беркетмәсе тәзелде, ул 2025 елның 15 ноябрендә 11 сәгать 00 минутта түбәндәге мәсьәләләр буенча: «Сез Зеленодольск муниципаль районының Күгәй авыл җирлеге Күгәй авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, I, II төркем инвалидлардан (ялгыз яшәүчеләрдән), көндезге бүлектә укучы студентлардан, җирлек территориясендә 3 елдан артык яшәмәүче затлардан тыш һәм җыеп алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүче түбәндәге эшләрне башкаруга 2026 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертү белән килешәсезме?:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (шул исәптән смета документациясен әзерләү һәм төзелеш контролен үткәрү, вак таш сатып алу, ташу, салу, шартнамә буенча эшләр өчен түләү);
- урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау;
- урамнарны яктырту җайланмасы;
- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү;

“ РИЗА” “КАРШЫ”

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган халык җыенында катнашучылар исемлегенә 297 кеше кертелгән, тавыш бирүдә 158 кеше катнашкан, бу 53% тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

җыенда катнашкан 158 кеше «РИЗА» позициясе өчен тавыш бирде;

«КАРШЫ» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Күгәй авыл җирлегенең Күгәй авылында халык җыены булып узды, халык җыены нәтиҗәләре – гамәлдә дип танырга.
2. «Сез Зеленодольск муниципаль районының Күгәй авыл җирлеге Күгәй авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, I, II төркем инвалидлардан (ялгыз яшәүчеләрдән), көндезге бүлектә укучы студентлардан, җирлек территориясендә 3 елдан артык яшәмәүче затлардан тыш һәм җыеп алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүче түбәндәге эшләрне башкаруга 2026 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертү белән килешәсезме?» дигән сорау буенча:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (шул исәптән смета документациясен әзерләү һәм төзелеш контролен үткәрү, вак таш сатып алу, ташу, салу, шартнамә буенча эшләр өчен түләү);
- урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау;

- урамнарны яктырту җайланмасы;
- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү карар кабул итәргә.

3. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Кугәй авыл җирлеге Кугәй авылы территориясендә яшәү урыны һәм даими яшәүче һәр балигъ булган кешедән 2026 елда үзара салым акчаларын 500 сум күләмендә кертергә.

4. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (шул исәптән смета документациясен әзерләү һәм тезелеш контролен үткәрү, вак таш сатып алу, ташу, салу, шартнамә буенча эшләр өчен түләү);
- урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау;
- урамнарны яктырту җайланмасы;
- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга ( http://pravo.tatarstan.ru ) Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында ( http://zelenodolsk.tatarstan.ru ) шулай ук Кугәй авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында: Кугәй авылы, Үзәк урамы, 29 йорт (администрация бинасы), Кугәй авылы, Тынычлык урамы, 20 йорт (мәдәният йорты бинасы).

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче Ф. Х. Хисаметдинова